| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БИМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БИМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2026 Бима авылы № 6

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел утыртмаларның бәясен исәпләү һәм компенсация яшелләндерү методикасын раслау турында» 25.08.2025 елның 10 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел утыртмаларның бәясен исәпләү һәм компенсация яшелләндерү методикасын раслау турында» 25.08.2025 елның 10 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3 пунктының 4 абзацын төшереп калдырырга;

2) 1.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Яшел утыртмаларга хокуксыз зыян китергәндә яисә юкка чыгарганда зыянны исәпләү Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 3.2 пунктының 2 абзацын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районының Бима авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Э.И. Михайлов